| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>БУТЛЕРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУТЛЕРОВКА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11.2021 е с.МокрыеКурнали **№1**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлегенең Юеш Көрнәле авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 105 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегенең Юеш Көрнәле авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 16 ноябренә 10:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан АМЙ бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Юеш Көрнәле авылы, Мәктәп ур., 9 й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Бутлеровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем

инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту;
- урамнарны яктырту;
- спорт мәйданчыгын төзекләндерү; спорт мәйданчыгын төзекләндерү;
- һәлак булганнарга һәйкәлне төзекләндерү;
- парк зонасын төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Бутлеровка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы** **И.Л. Хушанова**